**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл жирлеге БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы,
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2020 ел №7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 19.04.2012 ел № 42 (11.02.2015 ел №129-75, 11.09.2015 ел №149-84, 10.03.2016 ел №25-11, 30.03.2018 ел №86-44 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына

бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2020 елның 30 ноябре 16.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны- Сарлы авыл мәдәният йорты;

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Сарлы авылы, Үзәк урам, 68А йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча 2020 елның 12 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.Р.Шәрипов